**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статью 12 Закона Республики Татарстан «Об оказании бесплатной юридической помощи гражданам в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
8 июня 2026 года

**Статья 1**

Внести в статью 12 Закона Республики Татарстан от 2 ноября 2012 года № 73-ЗРТ «Об оказании бесплатной юридической помощи гражданам в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2012, № 11 (I часть); 2013, № 11 (I часть); 2014, № 1 – 2, № 12 (II часть); 2016, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 44 (часть I); 2018, № 1 (часть I); 2022, № 17 (часть I); 2023, № 3 (часть I), № 27 (часть I), № 56 (часть I), № 92 (часть I); 2024, № 18 (часть I); 2025, № 49 (часть I), № 75 (часть I); 2026, № 2 (часть I) следующие изменения:

1) часть 1 дополнить пунктом $8^{6}$ следующего содержания:

«$8^{6}$) лица, ходатайствующие о признании их вынужденными переселенцами, беженцами, признанные вынужденными переселенцами, беженцами либо получившие временное убежище на территории Российской Федерации, если они обращаются за оказанием бесплатной юридической помощи по вопросам, связанным с предоставлением мер социальной поддержки, признанием их вынужденными переселенцами, беженцами, предоставлением временного убежища на территории Российской Федерации или приемом в гражданство Российской Федерации;»;

2) часть 2 дополнить пунктом 22 следующего содержания:

«22) предоставление мер социальной поддержки лицам, указанным в пункте $8^{6}$ части 1 настоящей статьи, признание их вынужденными переселенцами, беженцами, предоставление им временного убежища на территории Российской Федерации, их прием в гражданство Российской Федерации, установление фактов, имеющих

юридическое значение, и восстановление утраченных документов, необходимых для решения данных вопросов.»;

3) часть 3 дополнить пунктом 7 следующего содержания:

«7) лицами, ходатайствующими о признании их вынужденными переселенцами, беженцами, признанными вынужденными переселенцами, беженцами либо получившими временное убежище на территории Российской Федерации, – по вопросам, связанным с установлением фактов, имеющих юридическое значение, и восстановлением утраченных документов, необходимых для получения мер социальной поддержки, признания вынужденными переселенцами, беженцами, предоставления временного убежища на территории Российской Федерации или приема в гражданство Российской Федерации.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
19 июня 2026 года
№ 34-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 8 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш); 2025, № 49 (I өлеш), № 75 (I өлеш); 2026, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $8^6$ пункт өстәргә:

«$8^6$) үзләрен көчләп күченеп килергә мәҗбүр булганнар, качаклар дип тану турында сораучы, күченеп килергә мәҗбүр булганнар, качаклар дип танылган йә Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны алган затлар, әгәр алар социаль ярдәм чаралары күрсәтүгә, үзләрен күченеп килергә мәҗбүр булганнар, качаклар дип тануга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирүгә яисә Россия Федерациясе гражданлыгы бирүгә бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр;»;

2) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 22 пункт өстәргә:

«22) әлеге статьяның 1 өлешендәге $8^6$ пунктында күрсәтелгән затларга социаль ярдәм чаралары күрсәтү, аларны күченеп килергә мәҗбүр булганнар, качаклар дип тану, аларга Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү, аларга Россия Федерациясе гражданлыгы бирү, юридик әһәмияткә ия булган

фактларны билгеләү һәм әлеге мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле булган югалган документларны торгызу.»;

3) 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

«7) үзләрен көчәнеп килергә мәҗбүр булганнар, качаклар дип тану турында сораучы, көчәнеп килергә мәҗбүр булганнар, качаклар дип танылган йә Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны алган затлар булсалар – юридик әһәмияткә ия булган фактларны билгеләүгә һәм социаль ярдәм чаралары алу, көчәнеп килергә мәҗбүр булганнар, качаклар дип тану, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү яисә Россия Федерациясе гражданлыгы бирү өчен кирәкле булган югалган документларны торгызуга бәйле мәсьәләләр буенча.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 19 июнь
№ 34-ТРЗ